ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.07.2024 с.Старое Дрожжаное № 293

«2021-2025 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 декабрендәге 695 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны актуальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 декабрендәге 695 номерлы (2024 елның 12 апрелендәге 154 номерлы карар редакциясендә) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең 2021-2025 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына муниципаль программасын раслау турында» карарына, Программаның «3.Максатлар һәм бурычлар» 3 бүлегенең икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле исемлекләр өстәп, үзгәреш кертергә:

«- кече һәм урта эшкуарлыкта мәшгульләрнең санын арттыру;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының сәнәгать мәйданчыгын һәм экспорт потенциалын үстерү;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сату базарлары белән тәэмин итү;

- социаль предприятиеләр һәм кече һәм урта эшкуарлыкның башлангыч субъектлары санын арттыру;

- өстенлекле тармаклардан (эшкәртү производствосы, авыл хуҗалыгы) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өлешен арттыру;

- халыкның, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык субъектларының һәм

махсус салым режимын кулланучы физик затларның дәүләт һәм муниципаль ярдәм чаралары турында мәгълүматлылыгын арттыру;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм үз-үзенә эшләүче гражданнарга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә кертелгән бизнес алып бару өчен яраклы объектлар санын ел саен кимендә 10 %ка арттыру, шул исәптән муниципаль милектәге файдаланылмый торган күчемсез милек объектларын, шул исәптән муниципаль милектәге предприятиеләргә һәм учреждениеләргә беркетелгән мөлкәтне, муниципаль милектәге һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен файдаланыла торган, нәтиҗәсез файдаланылган яисә мөлкәтне билгеләү буенча файдаланылмый торган мөлкәтне ачыклау максатында гамәлгә ашыру йомгаклары буенча.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов